**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.10.2024 № 1208

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә хезмәт өчен түләүнең яңа системаларын кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 18 августындагы 592 номерлы карары (2023 елның 6 ноябренә үзгәрешләр кертеп), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31 маендагы Карары нигезендә «Татарстан Республикасы дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында (2024 елның 24 июненә үзгәрешләр кертеп)412 номерлы", Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларын раслау турында” 2023 елның 25 июнендәге 2441/13 номерлыТатарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында " 2015 елның 07 декабрендәге под-9696/15 боерыгы белән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлегенең кызыксындыру түләүләрен (4 һәм аннан күбрәк төркемнәр) исәпләү өчен нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларын 1нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлегенең кызыксындыру түләүләрен (3 һәм аннан азрак төркемнәр) исәпләү өчен нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларын 2нче кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм аның гамәлдә булуы 2024 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы мәгариф оешмалары җитәкчеләренең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларын раслау турында " 2022 елның 30 маендагы 570 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин